**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
22.09.2025 № 1076

2026 елга "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты һәм “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга 2026 елга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсына мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 22 сентябрендәге 1076 номерлы карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Урнашкан җире | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Шәһәр җирлеге | 135849 |
| | Авыл җирлеге | 137122 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | Шәһәр җирлеге | 205458 |
| | Авыл җирлеге | 209941 |